**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“04” сентябрь 2018 ел** **№ 92**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 14 июнендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү Кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында”гы 55 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2017 елның 29 декабрендәге 477-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында”гы Федераль законының 15 маддәсенә үзгәреш кертү турында”гы Федераль закон нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2017 елның 14 июнендәге 55 номерлы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган, “Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертү турында:

Кагыйдәләрнең 98.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

98.9. туктап тору территориясенә инвалидларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итү. Транспорт чараларының һәр туктау урынында, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, I, II төркем, шулай ук III төркем инвалидлар йөртә торган транспорт чараларын һәм шундый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын түләүсез парковкалау өчен 10 процентттан ким булмаган (әмма кимендә бер урын) урын бүлеп бирелә. Күрсәтелгән урыннарны парковкалау өчен башка транспорт чаралары биләргә тиеш түгел.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк урамы, 1йорт;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Шәпкино авылы, Клуб урамы, 14 йорт, шулай ук хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

"Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге"
Башлыгы, "Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге"
Советы рәисе И.Х.Шиһабиев